РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Урсаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 60,
Азнакаевский район, с.Урсаево,
423318,
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 60 нчы йорт, Азнакай
районы, Урсай авылы, 423318
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «08 » ноябрь 2024 г.** **№ 5**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставының 15.1 ст. белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, хәрби операциядә катнашучыларның гаилә эгъзаларыннан, көндезге уку формасында укучылардан тыш, 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Урсай

авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылы торбаларын алыштыру,килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү,);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Урсай авылының Совет урамы буенча (мафлар сатып алу һәм урнаштыру, койма сатып алу һәм урнаштыру , Урсай авылының юлларын кардан чистарту).

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларга һәм җирлекнең рәсми сайтына кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә

Башлык З.Х.Рахимьянова